# Рәшит Бәшәр

**Тормыш юлы[1].**

Р.Бәшәр 1949 елның 7 октябрендә Татарстанның Кукмара районы Янил авылында туа. 1972 елда Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, Лениногорск районы Куакбаш сигезьеллык мәктәбендә балалар укыта, шәһәр профтехучилищесында директор урынбасары, заводта мастер булып эшли.

1979 елда Чаллы каласына күчеп килә. КамАЗ заводында диспетчер, оператор була.

1987 — 1989 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. Аннары «Таң йолдызы» газетасы редакциясендә бүлек мөдире, җаваплы сәркатип, КамАЗ нәшриятында мөхәррир, «Аргамак» журналында бүлек мөдире вазифаларын башкара.

Р.Бәшәр— Э.Касыймов, С.Сөләйманова исемендәге әдәби бүләкләр иясе, А.Алиш исемендәге премия лауреаты, 1985 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Әдәби эшчәнлеге.**

Р.Бәшәрнең беренче шигырьләре мәктәптә укыганда ук басыла башлый. Ул «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы һәм «Ялкын» журналы оештырган әдәби конкурсларда берничә тапкыр җиңеп чыга. Автор «Әйләнбәйлән» (1975), «Бәйрәм» (1977), «Яшел океан» (1981), «Ак әкият» (1986), «Ай кызының зәңгәр чиләге» (1990), «Сандугачлы бишек» (2000) исемле китапларында үзен лирик җанлы, әйләнә-тирәгә рәссам күзе белән караучы, табигатькә җан өрә белүче шагыйрь итеп танытты. Ул бик күп шигырьләрендә авыл табигатен нәни геройга мөнәсәбәттә, аның нечкә һәм самими күңел кичерешләре аша тасвирлый. «Яшел океан» исемле китабындагы шигырьләр табигатьтәге гүзәл фасылларның берсе яшел җәйгә багышланган. Андагы геройлар — табигатькә гашыйк сәяхәтчеләр генә түгел, ә шул сокландыргыч дәрьяга хуҗаларча карапучылар да. Автор шигырьдән шигырьгә табигатьнең төрле-төрле гүзәл һәм серле күренешләрен ача. Ул табигать хозурлыгында кешенең зурлыгын күрә, балаларга аңлаешлы итеп, шигъри бизәкләр белән моны тасвирлап бирә.

Авторның «Ярул абый», «Горурлык», «Куаныч», «Төзүчеләр», «Һавадагы абыйлар», «Яңа йорт», «Шәһәр төзим» һ. б. шигырьләрендә хезмәт темасы үтемле итеп, поэтик осталык белән ачылган. Кама буендагы каланы төзүчеләр әллә нинди пәһлеваннар түгел, ә резин итекләр белән яңгыр суын ерып килүче Ярул абыйлар, ә алар төзегән шәһәрдәге бер йортка бөтен бер авылны кертеп утыртырга була икән. Гомумән, шагыйрьнең бик күп шигырьләре КамАЗга, анда эшләүчеләргә багышланган. Р.Бәшәрнең көчле ягы — балалар күңелен аңлый, дөньяга алар күзе белән карый белүендә. Ул балалар дөньясын читтән генә күзәтеп тормый, гүя үзе дә малайлар, кызлар арасында йөри. Шуңа да шигырьдә сөйләнгән вакыйгаларны бала үзе кичергән хәл дип кабул итә.

«Джунглида» дигән шигырьдә тапкыр малай маймыллар белән «куыш-куыш уйный», «крокодил сыртына ятып су эчә», «ырылдавы да котны ала торган юлбарыслар белән» футбол уйный. «Чыпчыклар көләләр», «Әйләнә өй», «Язмыш», «Өй салалар осталар», «Дөяләр», «Сыбызгы», «Акчарлак», «Киләчәк», «Прәннек» шигырьләрендә нәтиҗә соңгы икеюллыкта ясала, ә «Энәкарак», «Сандугачлы ак инеш», «Коймаклы таба», «Гаҗәп көн», «Су тегермәне», «Көз башы», «Мин» дигән шигырьләрендә әсәрнең идеясе ахыргы юлда гына ачыла.

Кыскасы, кайсы шигырьдә нинди генә вакыйга турында сөйләнмәсен, алар бар да балалар психологиясенә, аларның фикер сөрешенә, кылган гамәлләренә тәңгәл килеп тора. Шагыйрь уңышлы алымнар белән бала күңелендә «балкып китәрлек» образ тудыра белә.

«Ни эшләп бетәрләр инде», «Бал суыртучы аю», «Бүрәнә белән бүдәнә», «Танышу», «Энәкарак», «Ат», «Бүген», «Мин бит татар егете», «Шомырт тотты якадан», «Картайган ат!» һ.б.ш. шигырьләрендә автор, уйнап, шаярып, бала күңеленә әхлак кагыйдәләрен салып куя.

Р.Бәшәрнең төрле милләтләр арасындагы үзара дуслык, чит мәмләкәт балаларының тормышлары, уй-хыяллары турында бик матур шигырьләр циклы бар. Шагыйрьнең гарәп малае Җәмил, Джон, Вова, Лилия, Пьерлары, Радик һәм Ринатлары гүя җир шары тирәли әйлән-бәйлән генә уйнамый, ә барлык халыкларны да төрле ямьсез күренешләрдән кисәтә, тату булып, дус булып яшәргә өнди. «Ай кызының зәңгәр чиләге», «Яшел чәчле кыз», «Абзар иясе» поэмаларындагы образлар — җәй, ак кыш, болыт, ак бишек, яшел алан, буран, кояш, колын — милли, космогоник һәм мифологик тәгълиматлар белән өртелеп бирелә.

Рәшит Бәшәр — чәчмә әсәрләр авторы да. Аның «Ак балык», «Ачык капка», «Яшел поезд», «Иртәгә дә яшисе бар», «Миләш», «Бер өйдә җиде кеше», «Минем әтиемне сугышта үтерделәр», «Җилдә тирбәлүче бишекләр...» исемле һәркайсы истә калырлык, ихлас язылган җыйнак повестьлары бар. Бу әсәрләр кешене, кеше белән бергә табигатьнең башка җан ияләрен рәнҗетүне бөтен жаны-тәне белән күрә алмау хисе белән сугарылган.

Р.Бәшәр әсәрләре балаларга аңлаешлы итеп язылган. Аның шигырьләрендә тыенкы, җылы юмор балкып китә. Сөйләм матурлыгы аның чагыштыруларына, сынландыруларына, автор сөйләменә дә күчкән. Әсәрләрендәге йомычкалар тургай булып атыла, зәңгәр КамАЗ су эчә, чәчәкләр кул чаба, юл буенда басып торган баганалар да кеше кебек уйлый белә.

Шигырьләрендә аллитерация («Җәй», «Туп»), каламбур («Төш», «Каймаклы таба», «Күл», «Басуга аяк басуга»), сурәт-шигырьләрнең дә («Тилгәнле җәй», «Мыраубикә сөт эчә», «Төнге агач», «Бакча») матур үрнәкләрен бирә.

[1] Мәкаләне журнал өчен Татар дәүләт гуманитар институты укытучысы **Илсөяр Мияссәрова** әзерләде.